ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 400-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 400-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1889-VI ДС

Проект
Татарстан
Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законы преамбуласына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш), «Татарстан Республикасының суверенлыгын» сүзләрен «Татарстан Республикасының дәүләтчелеген» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә («Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) туры китерү максатыннан эшләнде.

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында»
Татарстан Республикасы законы проектын
финанс-икътисадый нигезләү

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.